РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 25 июле 28 номерлы

**Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга тапшыру өчен муниципаль милек исемлегенә кертелгән муниципаль милкен (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен раслау турында» 2018 елның 23 гыйнварындагы 5 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Аренда шартларында муниципаль милекне нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга тапшыру өчен муниципаль милек исемлегенә кертелгән муниципаль милкен (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен раслау турында» 2018 елның 23 гыйнварындагы 5 нче номерлы карарына (алга таба – «карар») түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарны түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт белән тулыландырырга:

«1.1 Әлеге карарның 1 пунктында каралган тәртиптә муниципаль милекне арендага бирү мөмкинлеген билгеләү өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре исемлеген расларга (кушымта)»

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2019 елның 25 июлендәге
28 номерлы карарына
кушымта

**Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре исемлеге**

| ОКВЭД коды | Эшчәнлек төре исемнәре |
|---|---|
| 01.11 | Башка төркемләүгә кертелмәгән бөртекле, техник һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү |
| 01.21 | Мөгезле эре терлек үрчетү |
| 01.23 | Дуңгызлар үрчетү |
| 01.61 | Үсемлекчелек һәм терлекчелек өлкәсендә, ветеринария хезмәтләреннән тыш, хезмәт күрсәтү |
| 03 | Балыкчылык |
| 10 | Азык-төлек продуктлары җитештерү |
| 15.12.1 | Авыл хуҗалыгы кош-корты һәм куян ите җитештерү |
| 10.13 | Иттән һәм кош итеннән азык-төлек җитештерү |
| 10.3 | Бәрәңге, җиләк-җимеш һәм яшелчә эшкәртү һәм консервлау |
| 10.4 | Үсемлек һәм хайваннар майлары һәм туңмайлар җитештерү |
| 10.5 | Сөт продуктлары җитештерү |
| 10.61 | Он-ярма сәнәгате продуктлары, крахмал һәм крахмал продуктлары җитештерү |
| 10.9 | Терлекләр өчен әзер азык җитештерү |
| 10.8 | Башка азык-төлек продуктларын җитештерү |
| 14 | Кием җитештерү |
| 20 | Агач эшкәртү һәм агач эшләнмәләр һәм бөкеләр җитештерү, җиһаздан тыш |
| 68.32.1 | Бүләкләү өчен яки килешү нигезендә күчемсез милек белән идарә итү |

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р. Долотказина